МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

26.03.2019 г.Казань № _187-осн_

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы
министрлыгы карамагындагы
дәүләт белем бирү учреждениесе
җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга
һәм җитәкчесенә аттестация үткәрү турында
нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 51 статьясы, «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 12 февралендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчесенә аттестация үткәрү турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр Р.Ә.Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы
министрлыгының 2019 елның 26
мартындагы 187-осн номерлы
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчесенә аттестация үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчесенә аттестация үткәрү турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан гамәлгә куелган учреждение) җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчесенә аттестация үткәрү тәртибен һәм вакытларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәне куллану максатларында дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары, белем бирү оешмаларының җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында» 2013 елның 8 августындагы 678 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә «Җитәкчеләр» категориясенә кертелгән вазыйфа карый.

1.3. Аттестацияне үтәргә тиеш:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатлар һәм җитәкчесе (алга таба – белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатлар, җитәкчесе, Министрлык);

1.4. Аттестацияне үтми:

авырлы хатын-кызлар;

йөклелек һәм бала тудыру ялында булган хатын-кызлар (аларның аттестациясе ялдан чыккач, кимендә, бер ел узганнан соң үткәрелә);

өч яшькә җиткәнче бала карау ялында булган затлар (аларның аттестациясе ялдан чыккач, кимендә, бер ел узганнан соң үткәрелә);

авыру сәбәпле эш урынында дүрт айдан артык булмаган җитәкче.

Калган кандидатлар һәм җитәкче өчен аттестация – мәҗбүри.

1.5. Белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатлар эш урынына билгеләнгәнче мәҗбүри рәвештә аттестация узарга тиеш.

1.6. Аттестация җитәкчеләрнең һәм кандидатларның квалификация дәрәҗәләре

белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасы таләпләренә тәңгәл килү-килмәвен билгели.

1.7. Аттестациянең төп бурычлары:

белем бирү учреждениесе җитәкчесенең һәм кандидатларның белемнәрен, квалификациясен һәм һөнәри эшчәнлеген объектив бәяләү;

максатчан, өзлексез һөнәри үсешкә һәм шәхси камиллеккә этәргеч бирү;

идарә итү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү;

белем бирү учреждениесе җитәкчесенең һәм кандидатларның потенциаль мөмкинлекләрен файдалану перспективаларын ачыклау.

1.8. Аттестациянең төп принциплары – коллегиальлек, хәбәрдарлык, ачыклык, объективлык, дискриминациягә юл куймау.

1.9. Кандидатларга һәм белем бирү учреждениесе җитәкчесенә аттестацияне Министрлык төзегән аттестацияләү комиссиясе уздыра (алга таба – Аттестацияләү комиссиясе).

1.10. Кандидатларны һәм белем бирү учреждениесе җитәкчесен аттестацияләү процедурасын методик, аналитик һәм оештыру-техник яктан Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторы тәэмин итә.

## II. Аттестацияләү комиссиясе

2.1. Аттестацияләү комиссиясе иҗтимагый башлангычларда эшли.

2.2. Аттестацияләү комиссиясе эшенең төп принциплары булып компетентлылык, объективлык, хәбәрдарлык, мөстәкыйльлек, һөнәри әхлак кагыйдәләрен үтәү тора.

2.3. Аттестацияләү комиссиясе:

кандидатлар (кандидат) һәм белем бирү учреждениесе җитәкчесе хакында тәкъдим ителгән материалларны анализлый, шул исәптән аларның квалификация белешмәләрендә күрсәтелгән белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына һәм (яки) һөнәри стандарт таләпләренә тәңгәл килү-кимәвен тикшерә, педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә киртә булмаслык нигезләрнең, белем бирү өлкәсендә хезмәт итүгә чикләүләр юклыгын билгели;

кандидатларны һәм белем бирү учреждениесе җитәкчесен һәрьяклап, объектив өйрәнә;

эш нәтиҗәсендә җитәкченең, кадидатларның квалификация дәрәҗәсенең куелган таләпләргә туры клүе (туры килмәве) турында карар кабул итә.

2.4. Аттестацияләү комиссиясе хокуклы:

кандидатлардан (кандидаттан), белем бирү учреждениесе җитәкчесеннән, шулай ук тиешле оешмалардан, Министрлыкның профильле бүлекләреннән үз эшчәнлеге өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

соратып алынган документларны, материалларны һәм мәгълүматларны тапшыру вакытын билгеләргә;

кирәкле консультацияләр уздырырга;

составы Аттестацияләү комиссиясе тарафыннан расланган экспертлардан, белгечләрдән торган эшче төркемнәр оештырырга.

2.5. Кандидатларны һәм белем бирү учреждениесе җитәкчесен аттестацияләү вакытын Министрлык билгели.

2.6. Аттестацияләү комиссиясенең төп эшчәнлек формасы булып утырышлар санала. Аттестацияләү комиссиясе утырышының урыны, датасы һәм вакыты турында аның әгъзаларына хат яки телефонограмма белән хәбәр ителә.

2.7. Аттестацияләү комиссиясенең шәхси составы Министрлык боерыгы белән раслана.

Аттестацияләү комиссиясе составына Министрлык, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкиле (килешү буенча) керә.

Аттестацияләү комиссиясенең составы кабул ителәчәк карарларга йогынты ясарлык мәнфәгатьләр бәрелешенә мөмкинлек калдырмаслык итеп оештырыла.

Тәгаен аттестация узучыны аттестацияләү барышында аттестацияләү комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасында мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә алырлык турыдан-туры яки читләтеп шәхси кызыксыну туса, ул утырыш башланыр алдыннан моның турында хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта ул тәгаен аттестацияләнүче турында карар кабул итүдә катнаша алмый.

2.8. Аттестацияләү комиссиясе рәис, аның урынбасарлары, җаваплы сәркатип, Аттестацияләү комиссиясе әгъзаларыннан тора.

2.9. Аттестацияләү комиссиясе рәисе Аттестацияләү комиссиясе эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра, аның утырышларында рәислек итә, Аттестацияләү комиссиясе эшен оештыра, кабул ителгән карарларның үтәлүен гомуми контрольдә тота, Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә.

2.10. Җаваплы сәркатип:

аттестацияләнүчеләр тапшырган аттестацияләнүгә гаризаларны һәм башка документларны эшкәртә;

Аттестацияләү комиссиясе утырышларына хәзерлек эше алып бара;

Аттестацияләү комиссиясе әгъзаларына һәм аттестацияләнүче җитәкче һәм кандидатларга утырышның урыны, датасы һәм вакыты турында хәбәр итә;

утырышның көн тәртибен формалаштыра, аттестация документларын гомумиләштерә һәм аларны Аттестацияләү комиссиясенә тапшыра;

Аттестацияләү комиссиясенең утырышларында беркетмә алып бара;

аттестацияләү нәтиҗәләре буенча боерык проектларын әзерли;

аттестацияләү нәтиҗәләре буенча боерыклардан өземтәләр әзерли һәм алар белән кандидатларны һәм җитәкчене кул куйдырып таныштыра;

Аттестацияләү комиссиясе исеменнән сораулар һәм белдерүләр җибәрә.

2.11. Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары Аттестацияләү комиссиясе утырышларында шәхсән катнаша.

2.12. Аттестацияләү комиссиясе утырышы анда катнашучылар саны составының гомуми исәбендә өчтән икесеннән дә кимрәк булмаганда гына хокуклы булып санала.

2.13. Аттестацияләү комиссиясе карарлары Аттестацияләү комиссиясе утырышында катнашучы әгъзаларның ачык тавыш бирүе аша ачыкланган

тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, Аттестацияләү комиссиясе утырышында рәислек иткән кеше тавыш биргән карар кабул ителгән булып санала. Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары тәкъдиме белән карар яшерен тавыш бирү юлы белән дә кабул ителергә мөмкин.

Аттестацияләү комиссиясе карарлары рәис, аның урынбасарлары, җаваплы сәркатип, утырышта катнашкан Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары кул куйган беркетмәләр итеп формалаштырыла.

Кабул ителгән карар белән килешмәгән Аттестацияләү комиссиясе әгъзасы язма рәвештә үзенең аерым фикерен белдерергә хокуклы, ул Аттестацияләү комиссиясенең утырыш беркетмәсенә өстәлә.

Аттестацияләү комиссиясе карары нигезендә Аттестацияләү комиссиясе утырышыннан соң җиде эш көне дәвамында Министрлыкның аттестацияләү нәтиҗәләре турында боерыгы бастырыла.

Аттестацияләү нәтиҗәләре турындагы боерыктан өземтәләр аттестацияләнүчеләргә кул куйдырып тапшырыла.

Җитәкчене аттестацияләү нәтиҗәләре турындагы боерыктан өземтә аның шәхси эшендә теркәлеп саклана.

Аттестацияләнгән кандидат белән хезмәт шартнамәсе төзелгәндә, боерыктан өземтә аның шәхси эшендә саклана.

2.14. Нигезләмәдә билгеләнгән белем бирү учреждениесе җитәкчесен һәм кандидатларны аттестацияләү процедурасын бозу турындагы бәхәсләр Россия Федерациясе законнары нигезендә карала.

## III. Кандидатларны аттестацияләү тәртибе

3.1. Кандидатны аттестацияләү Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә аттестация уздыру турында Аттестацияләү комиссиясенә тапшырылган гариза (алга таба – гариза) нигезендә уздырыла:

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының белем бирү учреждениесенең эшчәнлеген координацияләүче беренче урынбасары (алга таба – кураторлык итүче министр урынбасары);

кандидат тарафыннан.

3.2. Кандидатны кураторлык итүче министр урынбасары тәкъдим иткән очракта, теркәп җибәрелә торган хатта кандидатның һөнәри, эшлекле сыйфатларына, һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә «Белем бирү учреждениесе җитәкчесе» һөнәри стандарт (квалификацион сыйфатлама) нигезендә формалашкан дәлилләнгән, һәрьяклы һәм объектив бәя булырга тиеш.

3.3. Аттестацияләү гаризасына түбәндәге документлар теркәлә:

хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документның күчермәсе;

белем алу турындагы документлар күчермәләре;

китерелгән мәгълүматларны тикшерүгә һәм эшкәртүгә кандидатның ризалыгы турында гаризасы (Нигезләмәгә 2 нче кушымта);

хөкемгә тартылу (тартылмау) һәм (яки) җинаять эзәрлекләве булу-булмау яисә

аклау нигезендә җинаять эзәрлекләве туктатылуы турында белешмә.

3.4. Документларның күчермәләре кандидатның эш бирүчесе имзасы белән раслана. Кандидат вакытлыча эшләмәсә, документларның күчермәләрен Аттестацияләү комиссиясе сәркатибе раслый.

3.5. Документларын тулы күләмдә тапшырмаган яки тутыру кагыйдәләрен бозган кандидатларга Аттестацияләү комиссиясе карары белән аттестация уздырудан баш тартыла.

3.6. Аттестацияләү комиссиясе гаризаны алган көннән башлап 10 эш көне дәвамында гаризага теркәлгән документларны һәм материалларны тикшерә.

3.7. Документларны тикшерү нәтиҗәсендә педагогика эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә каршы килә торган нигезләр һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә чикләүләр ачыкланган очракта, кандидатка аттестацияләү процедурасын узуга ризалык бирелми.

3.8. Аттестацияләүнең теләсә кайсы этабында гамәлдәге квалификация таләпләренә яки һөнәри стандартка тәңгәл килмәгән, педагогика эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә чикләүләр, белем бирү өлкәсендә хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә чикләүләр яки тапшырылган документларда ялган ачылган очракта, кандитатлар Аттестацияләү комиссиясе карары белән аттестация узмаган булып санала.

3.9. Белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга (кандидатка) һәм аттестация узарга тиешле җитәкчегә аттестациянең узу урыны, датасы һәм вакыты турында почта аша яисә телефонограмма белән аттестациягә хәтле 15 эш көненнән дә соңармыйча хәбәр ителә.

3.10. Кандидат Аттестацияләү комиссиясе утырышында шәхсән катнаша. Кандидат утырышта булмаса, аның кандидатурасы каралмый.

3.11. Аттестацияләү комиссиясе утырышында катнашу мөмкинлеге булмаса, аттестацияләү графигына кирәкле үзгәрешләр кертелә.

3.12. Аттестацияләү комиссиясе утырышында кандидат үзе булмаса яки ул белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына яраклы түгел дип танылса, ул аттестацияне кабаттан Аттестацияләү комиссиясе утырышы көненнән алып ике ел узгач кына узарга мөмкин.

3.13. Аттестацияләү комиссиясе кандидат белән әңгәмә уздыра һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына яраклы;

белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына яраклы түгел.

3.14. Кандидатны аттестацияләү нәтиҗәләре бер ел дәвамында үз көчендә кала.

3.15. Аттестацияләү комиссиясе карары белән белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына яраклы түгел дип табылган кандидатлар карар кабул ителү вакытыннан ике ел үткәч кенә аттестацияне кабаттан уза ала.

## IV. Белем бирү учреждениесе җитәкчесенә аттестация уздыру тәртибе

4.1. Белем бирү учреждениесе җитәкчесенә карата чираттагы һәм чираттан тыш аттестация уздырыла.

4.2. Җитәкчегә чираттан тыш аттестация Министрлыкның карары белән түбәндәге сәбәпләр булганда уздырыла:

җитәкче тарафыннан  берничә тапкыр документлар белән дәлилләнгән федеральъ һәм республика законнары бозылу;

белем бирү учреждениесендә белем алучылар тарафыннан укыту программаларын үзләштерү нәтиҗәләре динамикасының алдагы чор белән чагыштырганда документлар белән дәлилләнгән тискәре якка үзгәрүе;

белем бирү учреждениесе эше нәтиҗәләренең түбән күрсәткечләренә карата белем алучылар (аларның законлы вәкилләре) тарафыннан дәлилләнгән, расланган шикаятьләр;

белем бирү учреждениесе җитәкчесенең шәхси карары.

4.3. Белем бирү учреждениесе җитәкчесенә чираттан тыш аттестация уздыру турында карар министрның кураторлык итүче урынбасарының чираттан тыш аттестация уздыруның сәбәбе күрсәтелгән эш кәгазе яисә белем бирү учреждениесе җитәкчесенең Аттестацияләү комиссиясенә кергән гаризасы нигезендә кабул ителә.

4.4. Кураторлык итүче министр урынбасарының эш кәгазе нигезендә чираттан тыш аттестациягә җибәрелгән җитәкче Аттестацияләү комиссиясенә (Нигезләмгә 1 нче кушымта) гаризасын үзенә карата чираттан тыш аттестация оештыру турында карар чыкканнан соң биш эш көне эчендә тапшырырга тиеш.

4.5. Чираттан тыш аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестацияләү нәтиҗәләренең гамәлдә булу вакыты яңартыла. Элекке аттестацияләү нәтиҗәләренең гамәлдә булуы тукталыла.

4.6. Белем бирү учреждениесе җитәкчесенең чираттагы аттестациясе шулай ук җитәкченең Аттестацияләү комиссиясенә биргән гаризасы (Нигезләмгә 1 нче кушымта) нигезендә уздырыла:

хезмәт шартнамәсенең вакыты үткәнче биш айдан да иртәрәк түгел һәм ике айдан да соңга калмыйча – беренче тапкыр чираттагы аттестация узучы белем бирү учреждениесе җитәкчесе өчен;

элек билгеләнгән аттестацияләү нәтиҗәләренең гамәлдә булу вакытыннан биш айдан да иртәрәк түгел һәм ике айдан да соңга калмыйча – шул ук уку йортында биләгән вазыйфасына яраклылыкка чираттагы аттестацияне узган белем бирү учреждениесе җитәкчесе өчен.

4.7. Аттестацияләү гаризасына түбәндәге документларның күчермәләре теркәлә:

белем алу һәм аттестация узу алдыннан өч ел дәвамында алынган өстәмә һөнәри белем алу турында;

алдагы аттестация нәтиҗәләре турындагы боерыктан өземтә (булган очракта).

4.8. Аттестацияләү комиссиясенә чираттагы аттестацияне узу турындагы гаризаны үз вакытында тапшыру өчен аттестацияләнүче белем бирү учреждениесе җитәкчесе җавап бирә.

4.9. Белем бирү учреждениесе җитәкчесе гаризаны тапшырмаса яки әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында билгеләнгән вакыт узганчы ике айдан кимрәк вакытта тапшырса, Аттестацияләү комиссиясе белем бирү учреждениесе җитәкчесе адресына гаризаны тапшыру вакытын үтәмәүгә аңлатма сорап хат җибәрә һәм бу

факт турында кураторлык итүче министр урынбасарына хәбәр итә.

4.10. Белем бирү учреждениесе җитәкчесе нигезле булмаган сәбәп аркасында Аттестацияләү комиссиясенә гаризаны үз вакытында бирмәгән өчен, хезмәт законнары нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартылырга мөмкин.

4.11. Аттестацияләү комиссиясе гаризаны алганнан соң биш эш көне дәвамында аттестация оештыру турындагы мәгълүматны министрның кураторлык итүче урынбасарына җибәрә, соңгысы, үз чиратында, әзерлек эшләрен оештыра һәм Аттестацияләү комиссиясенә аттестацияләнүче җитәкчегә карата Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча таныклама (алга таба – таныклама) җибәрә.

4.12. Танықламага белем бирү учреждениесе җитәкчесенең аттестацияләүгә кадәр ике уку елы дәвамында «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» дәүләт урта һөнәри белем бирү бюджет мәгариф учреждениесе җитәкчесе эшчәнлеге күрсәткечләре исемлеген, эш нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын һәм премия бирү тәртибен раслау турында» 2012 елның 10 июлендәге 342-осн номерлы Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган критерийларны үтәве турында мәгълүмат булган аналитик белешмә кушымта итеп бирелергә тиеш.

4.13. Аттестацияләү процедурасын үткәрү дәвамлылыгы гаризаны алган көннән соң, Аттестацияләү комиссиясе карар кабул иткәнче 45 календарь көненнән артмаска тиеш.

4.14. Аттестацияләү комиссиясенә килгән таныклама белән белем бирү учреждениесе җитәкчесен җаваплы сәркатип аттестация уздыруга 14 календарь көненнән дә соңга калмыйча кул куйдырып таныштыра.

4.15. Таныклама белән танышканнан соң, белем бирү учреждениесе җитәкчесенең Аттестацияләү комиссиясенә үзенең өч ел дәвамындагы эшчәнлеген сыйфатлаган шәхси мәгълүматларны бирү, шулай ук танықламада турыдан-туры җитәкчесе китергән мәгълүматлар белән килешмәсә, тиешле дәлилләр китереп гариза язу хокукы бар.

4.16. Белем бирү учреждениесе җитәкчесе таныклама белән танышудан баш тартса, тиешле акт төзелә.

4.17. Белем бирү учреждениесе җитәкчесе

4.18. Нигезле сәбәпләр аркасында (авыру, командировка һ.б.) җитәкче Аттестацияләү комиссиясе утырышында була алмаган очракта, аттестацияләү графигына тиешле үзгәрешләр кертелә.

4.19. Нигезле булмаган сәбәпләр аркасында Аттестацияләү комиссиясенең утырышына килмәгән җитәкчегә аттестацияне комиссия аннан башка уздырырга хокуклы.

4.20. Аттестацияләү комиссиясе утырышы алдыннан белем бирү учреждениесе җитәкчесе Аттестацияләү комиссиясе әгъзаларына аттестацияләү процедурасын уздыруга бәйле өстәмә мәгълүматлар булу-булмавы турында хәбәр итә.

4.21. Аттестацияләү комиссиясе танықламада китерелгән аттестацияләнүче турындагы мәгълүматларны, таныклама белән килешмәү очрагында, аның дәлилле

гаризасын карый, шулай ук аның «Белем бирү оешмасы җитәкчесе» һөнәри стандарты (квалификацион сыйфатлама) таләпләренә яраклы булу-булмавына бәя бирә.

4.22. Аттестацияләү комиссиясе әгъзаларының кирәк очракта аттестацияләнүчегә аның вазыйфаларын үтәү белән бәйле сораулар бирү хокукы бар.

4.23. Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары уздырылган эш нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

үзе биләгән белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына яраклы;

үзе биләгән белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына яраклы түгел.

4.24. Белем бирү учреждениесе җитәкчесен аттестацияләү өч елга бер тапкыр уздырыла. Белем бирү учреждениесе җитәкчесенең вазыйфасына яраклы булуын раслау максатыннан, аттестацияләү вазыйфага билгеләнгәннән соң ел дәвамында уздырыла.

4.25. Үзенә карата белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфаларына туры килми дигән карар кабул ителгән җитәкченең гаризасы нигезендә, Аттестацияләү комиссиясенең кабаттан аттестация уздыру турында карар кабул итәргә хокукы бар. Аттестация уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында белем бирү учреждениесе җитәкчесенә әлеге Нигезләмәгә яраклы рәвештә хәбәр ителә.

4.26. Үзенә карата кабаттан аттестацияләү турында карар кабул ителгән белем бирү учреждениесе җитәкчесе Министрлык боерыгы белән аттестацияләүне уңышлы үткәнчегә кадәр бөтен вакытка эшеннән читләштерелә, белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфаларын башкару белем бирү учреждениесе җитәкчесе урынбасарларының берсенә йөкләнә.

4.27. Аттестацияләү комиссиясе тарафыннан үзенә карата биләгән вазыйфасына туры килми дигән карар кабул ителгән белем бирү учреждениесе җитәкчесе, хезмәт законнары нигезендә, эшеннән азат ителергә (алынырга) мөмкин.

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгы
карамагындагы дәүләт белем бирү
учреждениесе җитәкчесе
вазыйфасына
кандидатларга һәм җитәкчесенә
аттестация
үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

_________________________________(кая)
(Аттестацияләү комиссиясе атамасы)
_______________________________(кемнән)
(вазыйфага кандидатның яки вазыйфага билгеләнгән
затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________
(вазыйфа һәм учреждение атамасы)

ГАРИЗА

Минем документларымны каравыгызны һәм мине
___________________________________________________________________________
(вазыйфа һәм учреждение атамасы)
максатыннан аттестацияләвегезне үтенәм.

Үзем хакында түбәндәге мәгълүматларны белдерәм:
Туган ел, көн, ай ________________________________________________
Белем (кайчан нинди белем бирү учреждениесен тәмамлаган, алган белгечлеге һәм квалификациясе)____________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Дәүләт яки муниципаль идарә,
менеджмент һәм икътисад юнәлешләрендә
өстәмә һөнәри белем (яки квалификация күтәрү курслары)
___________________________________________________________________________

Гомуми эш стажы___ , шул исәптән педагог эше стажы___ ел,
җитәкче эше стажы___ ел, аттестацияләнәсе вазыйфада___ ел.
Бу учреждениедә __________________ елдан эшлим (яки эшләмәдем).
Хезмәт кенәгәсеннән өземтәне кушымта итеп бирәм (җитәкче вазыйфасына кандидатлар өчен)
Түбәндәге бүләкләргә, исемнәргә, гыйльми дәрәҗә, фәнни исемнәргә ия.
___________________________________________________________________________

ИКТ- технологияләр белән эш итү дәрәҗәсе (югары, канәгатьләнерлек, түбән) (кирәклесенең астына сызарга)

Түбәндәге документларны кушымта итеп бирәм: (санап чыгарга)
Квалификацион сыйфатлама таләпләре һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесенә кандидатларга һәм җитәкчесенә аттестация үткәрү турында нигезләмә белән таныш.

«____» _________ 20__ ел Имза ___________________
Кесә телефоны ____________________ Эш телефоны _____________

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгы
карамагындагы дәүләт белем бирү
учреждениесе җитәкчесе
вазыйфасына
кандидатларга һәм җитәкчесенә
аттестация
үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Шәхси мәгълүмталарны эшкәртүгә
җитәкче вазыйфасына кандидатның ризалыгы

______________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы
дәүләт белем бирү учреждениесе атамасы)

Мин, ___________________________________________________________,
(фамилия, исеме, атасының исеме)

________________________________________________ адресы буенча теркәлгән паспорт серия _________ № _________, бирелгән ________________________________, ирекле рәвештә, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә Татарстан Республиксы Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчесенә аттестация үткәрү комиссиясенә түбәндәге шәхси мәгълүматларны җыю, язып алу, системалаштыру, туплау, саклау, төгәллек кертү (яңарту, үзгәртү), өземтә ясау, файдалану, тапшыруны (тарату, бирү, файдалануга рөхсәт, блокировка, алып ташлау, юкка чыгару) кертеп, автоматлаштыру чараларыннан файдаланып яки андый чаралардан файдаланмыйча, эшкәртүгә (теләсә кайсы гамәлгә (операция) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасына) ризалык бирәм: фамилия, исем, ата исеме, туу датасы һәм урыны, гражданлык, элекке фамилия, исем, ата исеме, аларны үзгәртү датасы, урыны һәм сәбәбе (үзгәртү очрагында); хезмәт эшчәнлеге башыннан башкарган эш (берьюлы ике урында эшләүне, эшкуарлык һәм башка эшчәнлекне дә кертеп), хәрби хезмәт; дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр, орденнар һәм медальләр (кем бүләкләгән һәм кайчан), туган җире, эш урыннары, яшәү урыны буенча теркәү адреслары (тору урыны), паспорт (серия, номер, кайчан һәм кем биргән), шулай ук хезмәт эшчәнлеген башкаруга караган башка шәхси мәгълүматлар.

Югарыда күрсәтелгән шәхси мәгълүматларны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидат буларак мәҗбүри аттестация узу максатыннан эшкәртүгә тапшырам.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкның әлеге ризалыкны имзалаган көннән гамәлгә керүе белән таныш. Мин китергән мәгълүматларның дөреслегенә карата җаваплылык турында кисәтелдем. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кире кайтарырга мөмкин.

______________________ «__» ____________20__ ел

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгы
карамагындагы дәүләт белем бирү
учреждениесе җитәкчесе
вазыйфасына
кандидатларга һәм җитәкчесенә
аттестация
үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

_______________________________(кая)
(Аттестацияләү комиссиясе атамасы)

____________________________________

____________________________________

ТАНЫКЛАМА

____________________________________________________________________________

(белем бирү йортының атамасы, вазыйфа, тулы Ф.И.А.) белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына яраклы булу-булмауны ачыклау максатыннан аттестацияләнү өчен

I. Гомуми белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Туу датасы (көне, ай, ел) | |
| 2. | Белем турында мәгълүматлар (югары, кайсы һөнәри белем бирү учреждениесен тәмамлаган, тәмамлау датасы) | |
| 3. | Димплом буенча белгечлек | |
| 4. | Диплом буенча квалификация | |
| 5. | «Дәүләт һәм муниципаль идарә», «Менеджмент», «Персонал белән идарә итү» әзерлек юнәлешләре буенча белеме | |
| 5.1. | Әзерлек юнәлеше | |
| 5.2. | Уку йорты атамасы | |
| 5.3. | Укуның дәвамлылыгы | |
| 5.4. | Укуны тәмамлау датасы | |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Идарә итү эшчәнлеге профиле буенча өстәмә белем | |
| 6.1. | Атамасы | |
| 6.2. | Белем бирү учреждениесе атамасы | |
| 6.3. | Уку сәгатьләре саны | |
| 6.4. | Тәмамлау елы | |
| 7. | Гомуми хезмәт стажы (ел) | |
| 8. | Педагогик эш стажы (ел) | |
| 9. | Әлеге вазыйфада эш стажы (ел) | |
| 10. | Әлеге учреждениедә эш стажы (ел) | |
| 11. | Хезмәткәр аттестацияләнәсе вазыйфага билгеләнү датасы | |

II. Һөнәри эшчәнлектә төп казанышлар

| | | |
|---|---|---|
| 2.1. | Педагогик эшчәнлек буенча квалификация категориясе булу-булмау (атамасы, бирү туры боерык датасы) | |
| 2.2. | Бүләкләр булу-булмау (атамасы, елы) | |
| 2.3. | Гыйльми дәрәҗә булу-булмау (атамасы, елы) | |

2.4. Җитәкченең һөнәри, эшлекле сыйфатларына, һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә «Белем бирү оешмасы җитәкчесе» һөнәри стандарт (квалификацион сыйфатлама) нигезендә формалашкан дәлилләнгән, һәръяклы һәм объектив бәя (аттестацияләр арасындагы чорда) ___________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________

2.5. Тәкъдимнәр белән нәтиҗә _____________________________________________
_________________________________________________________________________
(билгән вазыйфага яраклы булу/булмавын тану мөмкинлеге турында мәгълүмат)

2.6. Кушымта – белем бирү учреждениесе җитәкчесенең аттестацияләүгә кадәр ике

уку елы дәвамында «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» дәүләт урта һөнәри белем бирү бюджет мәгариф учреждениесе җитәкчесе эшчәнлеге күрсәткечләре исемлеген, эш нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын һәм премия бирү тәртибен раслау турында» 2012 елның 10 июлендәге 342-осн номерлы Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган критерийларны үтәве турында мәгълүмат булган аналитик белешмә.

____ биттә 1 нөсхәдә

«___» ____________ 20___ ел
Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары

______________________________ ________________________
(имза) (тулы имза)

Таныклама белән таныш, риза «___» __________ 20__ ел

________________________________ ______________ ____________________
(Белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасы) (имза) (тулы имза)

Таныклама белән таныш, риза «___» __________ 20__ ел

________________________________ ______________ __________________
(Белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасы) (имза) тулы имза)